| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.03.2021 с.Старое Дрожжаное №92

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 44 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 сентябрендәге 632 номерлы карары (30.01.2015 ел, № 48/1 редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе турындагы Нигезләмәгә, түбәндәге эчтәлектәге IX өлеш өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«IX. Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу

9.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы астында Бүлек хезмәткәренең шәхси кызыксынуы, аларның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясарга мөмкин һәм шул чакта Бүлек хезмәткәренең шәхси кызыксынуы, хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре арасындагы каршылык барлыкка килергә мөмкин булган хәл аңлашыла.

9.2. Бүлек хезмәткәренең хезмәт бурычларын тиешенчә үтәүгә тәэсир итә яки йогынты ясый ала торган шәхси кызыксынуы астында, Бүлек хезмәткәренең хезмәт вазыйфаларыннан акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, яки мөлкәти характердагы хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә, үз-үзләренә яки өченче затлар өчен керем алу мөмкинлеге аңлашыла.

9.3. Бүлек башлыгы Гамәлгә куючыга(Оештыручыга) вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә бурычлы.

9.4. Бүлек хезмәткәре вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында Бүлек башлыгына хәбәр итәргә тиеш. Бүлек башлыгына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган мәгълүматлар исемлеге, әлеге белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе, Бүлек башлыгы тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д.А. Сатдинов